ГЛАВА ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“13 ” август 2018 ел | № 4

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгынын 2012 елнын 7 сентябрендэге " Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 7 нче номерлы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгынын 2013 елнын 20 мартындагы " Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»1 нче номерлы карарын гамэлдэн чыгару турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгының 2012 елның 7 сентябрендэге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 7 номерлы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгының 2013 елның 20 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы /И.Я.Хаев/